**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

«08» ноябрь 2019 ел Калмаш авылы № 5

**«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылында үзарасалым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирлеүзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирлеүзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. 2019 елның 20 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. 2019 елның 21 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Каенлы, Дуслык,, Салимгараев, Чияле, Тынычлык, Кояшлы, Күл буе, Төн як, Лазурная, Җиңүгә 70 ел, Фатих Амирхан, Чәчкәле, Муса Җәлил, Якут Метшин, Яшьләр, Төзүчеләр, Урманлы, Болынлы, Басу урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын билгеләргә.
3. 2019 елның 22 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Гагарин, Зөфәр Галиев, Үзәк урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының оченче этабын билгеләргә
4. 2019 елның 26 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Яңа, Сэйдәш, Тукай урамнарында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын билгеләргә
5. 2019 елның 27 ноябренә 18.00 сәгатькә Тукай муниципаль районы Калмаш авылы Советлар урамында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының бишенче этабын билгеләргә
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2020 елда яшәү урыны буенча Калмаш авыл җирлеге Калмаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сумм күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күпбалалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм анны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сумм күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

- Калмаш авылы - З. Галиев - Үзәк урамы – Яр Чаллы – Калмаш – Игенче автомобиль юллары арасындагы участокка тимер бордюр урнаштыру;
- Калмаш авыл җирлеге торак пунктларының юлларын ремонтлау;
- Юлларны ремонтлау өчен төзелеш материаллары сатып алу;
- Калмаш авыл җирлеге торак пунктларында урамнарны яктырту өчен СИП кабель һәм электр лампалары сатып алу һәм урнаштыру;

-Калмаш авылы Зөфәр Галиев урамы буенча күпфатирлы йортларда канализация проектын эшләү;

«ӘЙЕ» «ЮК».

7. Гражданнар җыенының биш этабын да түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Калмаш авылы, Үзәк урамы, 32, Яшьлек мәдәният йорты

8. Халык җыенын оештыручы итеп Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

9. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

10. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Калмаш авыл җирлеге Башлыгы Р.К.Габдуллина